**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 елның 3 марты № 218

«Кама Тамагы муниципаль районы территориясендә сайлау участокларын төзү турында» Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 11 апрелендәге 241 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 2.1 пунктының «б», «г» һәм «д» пунктчалары нигезендә, сайлау участоклары исемлеген һәм аларның чикләрен, җирле шартларны исәпкә алып, төгәлләштерү максатларында, Кама Тамагы муниципаль районының территориаль сайлау комиссиясе белән килештереп,Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Кама Тамагы муниципаль районы территориясендә сайлау участокларын төзү турында» Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 11 апрелендәге 241 номерлы карары кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 22 пункт 1645 номерлы сайлау участогы бетерелүгә бәйле рәвештә үз көчен югалтты;

1.2. 23 пункт 1646 номерлы сайлау участогы бетерелүгә бәйле рәвештә үз көчен югалтты;

1.3. 33 пункт 1656 номерлы сайлау участогы бетерелүгә бәйле рәвештә үз көчен югалтты;

1.4. Кушымтаның 20 пунктын түбәндәге редакциядә чыгарырга:

«20. 1643 нче участок. Үзәк - авыл мәдәният йорты, Каратал авылы, Күпер ур., 5 йорт, тел. 30-4-65, ш.55.282462, д.48.831176 .

Сайлау участогы чикләренә Каратал авылы, Атабай авылы, Бишалаб авылы керә.»;

1.5.Кушымтаның 32 пунктын түбәндәге редакциядә чыгарырга:

«32. 1655 нче участок. Үзәк - авыл мәдәният йорты, Кирельский авылы, Совет мәйданы, 13 йорт, тел. 36-7-35, ш.55.136757, д.49.144231 .

Сайлау участогы чикләренә Кирельский авылы, Мордва Каратае авылы, Ишем авылы йортлары керә.»;

1.6. Кушымтаның 39 пунктын түбәндәге редакциядә чыгарырга:

«39. 1662 нче участок. Үзәк - фельдшер-акушерлык пункты бинасы, Олы Бортас авылы, Муса Җәлил урамы, 18А йорт, тел. 33-6-18, ш.55.271330, д.48.912378.

Сайлау участогы чикләренә Олы Бортас авылы, Кече Бортас авылы йортлары керә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р. М. Заһидуллин